**Профсоюз председателе отчёты 2022 ел**

Мин, Муртазина Гульназ Маулетхан кызы, шушы балалар бакчасында 2021нче елның 1нче ноябреннән профсоюз рәисе вазифасын үтим. Эшләү дәверендә булдыра алганча әлеге вазифага намуслы карарга тырыштым. Безнен Профсоюз комитетына жирлектәге 5 авыл керә: Аш-Бужи, Адай, Зур Сәрдек, Купка, Чишмәбаш авыллары балалар бакчалары.

Администрация белән килешенеп 2020-2023нче елларга Коллектив Килешүе төзелде. Хәзерге көндә әлеге документ профсоюз әгъзаларын яклаучы иң төгәл документ. Анда күрсәтелгән таләпләрнең барысы да диярлек үтәлә. Мәсәлән: бушлай медосмотр, тиешле эш вакыты һәм эш урыны белән тәэмин итү, вакытында ял алу, эш урынының куркынычсыз һәм төзек булуы, вакытында эш хакы алып бару һ.б.

Шушы дәвердә балалар бакчасында эшләү өчен еллык план төзедек, аны кабул иттек, ел дәвамында алга куелган планнарны үтәргә тырыштык.

Бакчабызда бик матур традиция – юбилярларны котлау, бәйрәм кичәләре яшәп килә. Бу билгеле, һәр юбилярның үз теләгенә карап үткәрелә. Ни генә булмасын, үзең күп еллар эшләгән коллектив белән бәйрәм кичәсе үткәрү бик матур күренеш. Ул искиткеч матур истәлекләр белән күңелгә кереп кала.

Безнең бу вакыт аралыгындагы Исмагилова Вәсилә Шамил кызы 55 яшьлек юбилеен билгеләп үтте. Минемуллина Дания Ибрахим кызын 2022 елда олылап лаеклы ялга озаттык.

Бу бәйрәмнәрдән кала әле безнең ел да үткәрелә торган бәйрәмнәребез бар – 8 март, тәрбиячеләр көне, яңа ел бәйрәме. Бу бәйрәмнәрне оештырып үткәрү бакча хезмәткәрләре һәм профсоюз бюджеты өстенә йөкләнгән. 8 Март һәм укытучылар көненә берникадәр акча алынса, Яңа ел бәйрәменә калган барлык акча алынып бетә. Бу бәйрәмнәрне оештырып үткәрергә булышкан өчен барлык кызларга да рәхмәт сүзе әйтәсем килә.

Шулай ук якын туганнарын югалткан хезмәткәрләргә материаль ярдәм күрсәтелде. Каюмова Гөлназ Нурсиль кызының, Ханафина Голузэ Зиннатулла кызының, Магьсумова Нурсия Равиль кызының, Фатхуллина Гөлүсә Рафил кызының, Закирова Дания Харис кызының кайгыларын уртаклаштык.

Профсоюз комитеты председателе: Муртазина Г.М.